**Ләбиб Лерон**

**Борчак шыттырам**

# ИКЕНЧЕ БОРЧАК
Шалтмылтфильмнар

Рәссамы ***Фәрит Муллахмәт***

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)6
Л47

**Леронов Л. Л.**

Борчак шыттырам : Икенче борчак : Шалтмылтфильмнар / Ләбиб Лерон.— Казан : Мәгариф, 2006.— 35 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1570-1

ISBN 5-7761-1570-1
© «Мәгариф» нәшрияты, 2006
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2006

## ИКЕ ТЫЧКАН БАЛАСЫ

Кичә-бүген заманда яшәгән, ди, ике тычкан баласы — Тәпи белән Шәпи.

Беркөнне болар Зәңгәр күлдә балык тотарга уйладылар.

Икесенә ике кармак алдылар да киттеләр Зәңгәр күлгә.

«Балык тотсалар — балыкларын, тотмасалар, үзләрен ашармын!» — дип, болар артыннан кача-поса Актәпи иярде.

«Актәпине эләктерергә җай чыкты!» — дип сөенде Муйнак.

Тычканнар су буена килеп җиттеләр дә суга кармакларын салдылар.

Шәпи кармагының калкавычы бата-калка башлады.

«Сөен, сөен! Мин эләктергәч, нишләрсең микән?» — дип, Муйнак Актәпигә якынлаша башлады.

Шәпинең, балык урынына сыңар ботинка сөйрәп чыгаргач, кәефе төште.

«Мин ботинка ашамыйм!»— диде дә Актәпи тычкан балаларына ыргылды.

Яшеренгән урыныннан чыгып, Муйнак Актәпи артыннан томырылды.

Тычкан балалары, кармакларын ташлап, Актәпигә каршы бастылар.

«Ә мин... мин... койма башына үрмәләүче!» — дия-дия, Актәпи артка таба чигенә башлады.

«Мин монда ялгыш кына килеп эләктем»,— дип, Муйнак та тизрәк таю ягын карады.

«Бердәмлектә — безнең көч!» — дип, ике тычкан баласы — Тәпи белән Шәпи чичичиләп-хихихиләп калдылар.

## КУЯНША БЕЛӘН БҮРЕТДИН

Кичә-бүген заманда яшәгән, ди, куян малае Куянша белән бүре малае Бүретдин.

Беркөнне болар, вилсәпидләргә атланып, урманда күңел ачып йөриләр икән.

Кинәт болар, бер төпкә бәрелеп, җиргә мәтәлделәр.

Якындагы бер куак артыннан елак тавыш ишетелде.

Куянша белән Бүретдин капкынга эләккән төлке малаен күреп алдылар.

Төлке малаен капкыннан азат иткәч, Куянша белән Бүретдин ары киттеләр.

Шулчак бер чокырдан янә ярдәм сораган тавыш ишетелде.

Куянша белән Бүретдин чокырдан чыгарга азапланган керпе малае Энәлине күреп алдылар.

Куянша Энәлине чокырдан тартып чыгарды.

Куянша белән Бүретдин ары юл тоттылар. Бер аланга килеп чыктылар.

Алан уртасында кушкаен үсеп утыра иде.

Бүретдин кушкаен арасына кысылып калды.

Куянша, бәлагә тарыган Бүретдинне ташлап, читкәрәк киткәндәй итте.

Бәлагә тарыган дустын нишләп ташлап китсен инде Куянша — килде ярдәмгә.

Бүретдингә бик-бик оят булды.

## АВЫЛ ЭТЕ МУЙНАК

Авыл эте Муйнак шәһәргә кунакка килде.

Муйнак якын туганы Актүшләрдә тәм-томнар белән сыйлангач, урамга чыкты.

Муйнакка Актүш тә иярде.

Циркның ни-нәрсә икәнен белмәсә дә, Муйнак шундук ризалашты.

Юл аркылы чыкканда чүт машина астына эләкмәде Муйнак.

— Юл аша җәяүлеләр чыга торган урын бу. «Зебра» дип атала,— дип аңлатты Актүш.

Актүш: «Әйдә, трамвай белән барабыз!» — дип әйтеп тә бетермәде, Муйнак трамвай артындагы баскычка барып тотынды.

— Анда тотынып барырга ярамый! — дип һау-һаулады Актүш.

Трамвайдан төштеләр.
— Юл аркылы чыкканда тирә-ягыңа каран! — дип кисәтте Актүш.

Муйнак янә элдерде.
— Ашыкма! Урамның теге ягына чыгарга кирәк безгә! — дип кычкырды Актүш.

Муйнак тагын машина астында кала язды.

Муйнак әле юл уртасыннан, әле юл читләтеп чаба башлады. Машиналар бер-берсенә бәрелә язып, чыелдап туктадылар.
— Синең аркада авария була язды бит! Тротуардан гына бар! — дип кычкырды Актүш. Муйнак ишетмәде.

Муйнак белән тәки бер-бер хәл буласы иде, ярый әле аны милиционер абый туктатып өлгерде.

— Цирк күрсәттең син миңа! — дип шелтәләде Актүш Муйнакны.

## БЕЛЕМДӘР БЕЛӘН ТЕЛЕМДӘР

Яшәгән, ди, яши, ди, Белемдәр белән Телемдәр исемле ике мәче.

Белемдәр бик белемле, Телемдәр бик телгә беткән.
Бик мактанчык, бик сүзчән икән.

— Бүген мәктәпкә укырга барабыз! —диде Белемдәр Телемдәргә.

— Үзем белгәнне синңа да өйрәтә алам,— дип мактанды Телемдәр.
Белемдәр белем алып, Телемдәр тырай тибеп, бер ел үтеп тә киткән.

— Синең белән уйнарга вакытым юк, дәрес хәзерлим,— диде Белемдәр.
— Әйдә күлгә барабыз! — диде беркөнне Белемдәр Телемдәргә.

— Укысаң, белер идең, — диде Белемдәр. — Күлдә су коенып, балык тотып була.

— Беркөнне без урманга бардык,— диде Белемдәр.

— Мәктәпкә укырга йөрсәң, күп нәрсәләрне белер идең әле син,— диде Белемдәр.

— Без быел Әкиятстан иленә сәяхәткә барабыз! — диде Белемдәр.

— Минем дә Әкиятстан илен күрәсем килә! — диде Телемдәр.

— Киттек, алайса, мәктәпкә — белем алырга! — диде Белемдәр.

## ӘКИЯТЧЕ МАЛАЙ

Әкиятләр укый торгач,
Тәки шомардым, малай:
Ошбу әкиятне үзем
Уйлап чыгардым, малай.

Борын-борын заманнарда
Түгел, бүген заманда
Яшәгән, ди, Кәҗә, Сарык...
Яшиләр, ди, һаман да.

Сарык бик акыллы икән,
Кәҗә аңгыра икән.
Сарык ак сакаллы икән,
Кәҗә саңгырау икән.

Берчак, урманда йөргәндә,
Аю башы тапканнар.
Аю башы: «Сәлам!»— дигәч,
Болар куркып чапканнар...

Бераз чапкач, хәл-тын алгач,
Сарык: «Ми-ки-ки!»— дигән.
Кәҗә, мескен, ишетмәгәч:
— Ул баш — синеке!— дигән.

Шуның белән шул: Кырлайга
Болар кайтып киткәннәр.
Вилсәпидләре ватылып,
Көчкә кайтып җиткәннәр...

Тагын борын заманнарда,
Авыз-колак чакларда,

Яшәгән Былтыр, Шүрәле
Сезнең-безнең якларда.

Шүрәле урманчы икән,
Былтыр — чүкеч остасы.
Бер мәлне болар урманда
Очрашканнар, кыскасы.

Бер ботакның булган икән
Нечкә генә ярыгы...
— Кети-кети уйныйк!— дигән
Шулчак урман сарыгы.

Былтыр-оста шүрләп калган,
Дер-дер килгән, кыскасы.
— Гафу ит, Шүрәле абзый,—
Дигән чүкеч остасы.

Ярыкка үз бармакларын
Былтыр кыстырган шулчак.
«Шүрәле быел кысты!»— дип,
Былтыр кычкырган шулчак.

Менә шул... Әкиятемне
Тагын укып алыгыз.
Тукай абый язган белән
Аермасын табыгыз.

## ӨЛГЕРҖАН ҺӘМ СИМЕРҖАН

Бүген-кичә заманда,
Син бәләкәй чакларда,
Ике малай яшәгән, ди,
Безнең-сезнең якларда.

Малайларның берсенең
Исеме Өлгер булган.
Икенчесе — Симерҗан, ди,
Кыскартсак, Симер булган.

Өлгерҗан әнисенең
Һәр йомышын үтәгән:

Казлар куган, су китергән,
Чүп утаган түтәлдән.

Мин — малай дип тормаган,
Савыт-саба юышкан.
Әтигә дә, бабайга да,
Әбигә дә булышкан.

Китаплар да укыган,
Биергә дә өйрәнгән.
Кечкенә энекәшенә
Әкиятләр сөйләгән.

Шашка, шахмат уйнаган,
Сәхнәләрдә җырлаган.
Тагын бик күп һөнәр белгән...
Кыскасы, тик тормаган.

Инде килик Симергә,
Улниләр эшли икән?
Улмы? Ул инде күптәннән...
Ятактан төшми икән.

Авыр чир йоккан аңа —
Бик каты чирли икән:
Ике сәгать ашагачтын,
Бер сәгать тирли икән.

Торып йөрер хәле юк —
Торса, бик тиз арый, ди.
Йокламаган чакта гына
Телевизор карый, ди.

Ашаганда хәтта ки
Кашык тоталмый икән.
Тук чагында һич кенә дә
Ризык йоталмый икән.

Үзе, бик түземсезләнеп,
Сабантуйны көтә, ди.
«Сабантуйда көрәшергә
Исәп бар!» — дип әйтә, ди.
Белмим, белмим... Шул синең

Сүзне тыңласа инде:
«Хәрәкәттә — бәрәкәт!»не
Үзе аңласа инде...

## БИЧУРА ҺӘМ ШӘЛӘЙ-ВӘЛӘЙ

*Борынгылар бичураны күәс чиләге рәвешендә күзаллаганнар.*

Элек-элек заманнан
Күп тә түгел, ди, алай...
Яшәгән, ди, бер малай,
Исеме — Шәләй-Вәләй.

Иртәдерме, кичтерме,
Менә бервакыт, кинәт,
Мич башыннан идәнгә
Дөп итеп төште кисмәк.

Җен-фәләнме төчкерде —
Кисмәккә җан-көч керде.
Күр, кара бичарага —
Әверелде Бичурага.

Әллә инде куркудан,
Әллә инде өркүдән
Өнсез калды бит малай,
Телсез калды бит малай!

Шәләй-Вәләй ни күрсен —
(Әйтәлмәде: «Тукта, син!») —
Ялт иттерде Бичура
Шәләй-Вәләй боткасын.

Булган барча ризыкны
Ялт иттерде Бичура.
Ашсыз калды, ач калды
Шәләй-Вәләй бичара.

«Бүген бездә Сабантуй,
Бүген бездә җыен!»— дип,
Шулвакыт Бичураның
Дус-ишләре җыелды.

«Кети-кети уйныйк»,— дип,
Шүрәле йөри чабып.
Җен-җүләр күкәй эзли,
Авызга кашык кабып.

Аждаһа авызыннан
Өзлексез ут бөркелә.
Тиле Дию малае
Бер елый да бер көлә.

Албастылар көрәшә,
Пәри мәтәлчек ата,
Убырлы карчык идәндә
Үкереп елап ята.

Бичура-бичараның
Хәлләре мөшкел иде.
Шәләй-Вәләй үзе дә
Бигрәк мескен иде.

Шулвакыт Шәләй-Вәләй
Уянып китте кинәт.
Һәм күрде мич башында
Алагаем зур кисмәк.

## СУГЫШ ЧУКМАРЫ ҺӘМ ТЫНЫЧ МАЛАЙ

Матур, ямьле җәйләр үткәч,
Кергәч алтын көзләргә,
Җайлап кына сөйлим әле
Бер әкият сезләргә.

Коры җиргә, иплән-сипләп,
Судан күпер салганда,
Яшәгән, ди, ике малай
Кичә-бүген заманда.

Берсе — сугыш чукмары, ди.
Берсе — тыныч малай, ди.
Беренчесе көчсезләрне
Егып кына сала, ди.

Нәниләрнең тәм-томнарын
Тартып кына ала, ди.
Кызларны да кыерсыткан
Менә шундый малай, ди.

Тыныч малай исә аннан
Эше-шөгыле белән
Аерылып торган, хәтта
Холык-фигыле белән!

Эшләгәндә ут уйнаткан,
Матур итеп уйнаган.
Җитезлектә-өлгерлектә
Бер дә кимен куймаган.

Рәнҗетмәгән нәниләрне,
Кызларга да тимәгән.
Сугыш чукмары шикелле:
«Сез — мокытлар!» — димәгән...

Беркөн шул малай янына
Килгән сугыш чукмары.
Күз алдына китергән ул
Ничек шәпләп тукмарын...

Бәйләнүен бәйләнгән ул,
Орынуын орынган...
Ник сугыша башлавына
Үкенгәндер соңыннан.

Тыныч малай аны җирдән
Күтәргән, ди, нык итеп.
Сизми калган теге малай
Утырганын лып итеп!

Ишеткән ул: «Без тынычта
Аттан артык эшлибез».
Бел, син, шуны: «Без сугышта
Юлбарыстан көчлебез!»

Тыныч малай шулай дигән —
Тукай абыйча әйткән.

Теге малай аңлагандыр,
Син дә аңладың микән?!

## ЯШЕЛ КЫШ БАБАЙ

Күптәндерме, түгелме —
Төгәлен белмим, малай...
Яшелстан илендә
Яшәгән Яшел бабай.

Бабайның сакалы да,
Чәче дә яшел икән.
Аерылмас юлдашы —
Мәче дә яшел икән.

Ап-ак карлар бу илдә
Бөтенләй яумый икән.
Малай-шалай ел буе
Чирәмдә ауный икән.

Бу илгә дә елга бер
Яңа ел килә икән.
Яңа елның килгәнен
Һәр бала белә икән.

Читкә киттек, хуш иттек —
Сүз бит бабай турында:
Яшел бабай бер көнне
Чыккан сәфәр юлына.

Иярткән мәчесен дә:
— Ашыгыйк, әйдә!— дигән.
Киткән болар, киткәннәр
Яңа ел бәйрәменә...

Юлда барган чагында...
Үзгәргән дөнья кинәт!
Дөнья акка әйләнгән —
Чын!— Түгел бу әкият.

Дөнья агын ак та соң,
Бер дә җылы түгел, ди:

Бабай яман калтырый,
Мәче дер-дер дерелди...

Менә шулай бу илгә
Көтмәгәндә кыш килгән.
Яшел бабай, әлбәттә,
Кыш килгәнен төшенгән.

Шуннан бабай әфсенләп:
— Әчтер-печтер, хи!— дигән.
Мәче һәм бабай шулчак
Җылы, ап-ак тун кигән.

Күрә бабай һәм мәче:
Балалар да киемнән...
Җылы кием киюгә
Олылар да сөенгән!
Яшел бабай үзе дә
Һич көтмәгәндә генә...
Әнә шулай кыш килгән
Яшелстан иленә.

## ГАРМУНЧЫ ШҮРӘЛЕ

Ирек гөмбә-җиләкләр
Җыеп йөргән чагында,
Кинәт урман эченнән
Дәртле бер көй агылды...

...Шаккатудан Ирекнең
Дөп-дөп типте йөрәге:
Бер агачка утырып,
Гармун уйный Шүрәле!

Кич булды да төн җитте —
Һаман уйный Шүрәле...
Тыңлаучы булгангамы,
Уйнап туймый Шүрәле!

Шүрәле, җырлый-җырлый,
Таң атканчы уйнады...
«Шәп гармунчы Шүрәле!»

Ирек шулай уйлады.

**ЭЧТӘЛЕК**

Ике тычкан баласы ............................................... **3**
Куянша белән Бүретдин ............................................... **7**
Авыл эте Муйнак ...............................................**11**
Белемдәр белән Телемдәр **...............................................15**
Әкиятче малай ............................................... **19**
Өлгерҗан һәм Симерҗан **...............................................22**
Бичура һәм Шәләй-Вәләй **...............................................25**
Сугыш чукмары һәм тыныч малай **...............................................28**
Яшел Кыш бабай ...............................................**31**
Гармунчы Шүрәле ...............................................**34**

Литературно-художественное издание
Для младшего школьного возраста

**Лерон** Лябиб
*(**Леронов** Лемон Леронович)*

**ЛАПША НА УШИ**
**КНИГА ВТОРАЯ**
*Комиксы*

Казань. Издательство «Магариф». 2006
*На татарском языке*

Әдәби-нәфис басма
Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

**Лерон** Ләбиб
*(**Леронов** Лемон Леронович)*

**БОРЧАК ШЫТТЫРАМ**
**ИКЕНЧЕ БОРЧАК**
*Шалтмылтфильмнар*

Редакторы *Л. Ә. Гыйззәтуллина*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда
биткә салучысы *М. И. Данилевская*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Л. Р. Вафина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 22.11.2006. Форматы 70x84$^{1}/_{16}$. Шартлы басма табагы 2,45. Нәшер-хисап табагы 1,73. Тиражы 2000 д. Заказ З-1015.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.